**Рәис ГЫЙМАДИЕВ**

# КАМАЗЫМ

Кышның шыксыз салкыннарын,
Җәйнең комлы тузанын.
Онытмамын беркайчанда
Син – яшьлегем, КамАЗым.

Минем үзем торган җирләр,
Балаларым – туган җир:
КамАЗ булып үсеп чыкты
Балчыгына тамган тир.

Үзәк урамында синең
Төрле-төрле агачлар,
Һәр яз саен шау-чәчкәгә
Күмелә алмагачлар.

Дөнья күләмендә КамАЗ
Булса да тик бер тамчы,
Яр Чаллы, безнең йөрәктә
Син гел яшь булып калчы!